Scientific Chronicles of the Turkic World
Төрки дөнья фәнни хроникасы
Научная хроника тюркского мира

# LATEST EVENTS IN 2014

In 2014, Kazan became the cultural capital of the Turkic world hosting an international conference “A Phenomenon of the Tatar Jadids: Shigabuddin Mardzhani, Rizaetdin Fakhretdin, Musa Dzharullah Bigiyev”. It was a large international event to take place at the Institute of International Relations, History and Oriental Studies, Kazan Federal University on April 18-19.

The Turkish partners represented by Istanbul center “Dersaadet”, leading universities of Turkey, and academicians initiated the conference and contacted Kazan Federal University with the proposal to organize the event in Kazan. Kazan Federal University was chosen as the conference venue because this oldest educational institution occupies the leading positions in the field of Oriental Studies, Turkology and Tatar Studies.

About 70 participants from Turkey took part in the event – Kazan has never seen such an impressive number of researchers working in the field of Tatar Studies! The conference brought together almost all experts engaged in Tatar studies. Kazan scholars, representatives of specialized institutes of Tatarstan Academy of Sciences, other higher education institutions of Tatarstan capital, academicians of the Russian Islamic Institute, the Muslim Spiritual Board of the Republic of Tatarstan, and many other scholars participated in this event.

The conference lasted two days, the program comprised a wide range of issues related to the history of the Russian-Turkish relations, Turkic culture and the role the famous Tatar public and religious figures played in the renovation processes of Turkic-Muslim society at the end of $19^{th}$ – beginning of the $20^{th}$century. The conference proceedings were divided into three thematic sections devoted to Sh.Mardzhani, R.Fakhretdin, M.Bigiyev.

Prominent Turkish scientists specializing in studying Mardzhani’s life and research presented in Section 1. Their reports were devoted to the unique and multifaceted activities of the man who was a Jadid movement harbinger. Mardzhani was described as an educator, religious figure, historian, philosopher and enlightener whose ideological and philosophical views and activity remain a noticeable phenomenon in the history of the Turkic people.

Speeches, delivered at Section 2, were devoted to another outstanding scientist-theologian and encyclopedist of the late$19^{th}$ – beginning of the $20^{th}$ century Rizaetdin Fakhretdin, and were of great interest for the audience. It was noted that R.Fakhretdin was projected as a humanist in his social and philosophical views, he paid great attention to the issues of morality, justice and equality, and devoted many of his works to the issue of women in Muslim society and family.

Many new and interesting things were revealed at Section 3 devoted to the outstanding Tatar theologian and reformer Musa Dzharullakh Bigiyev. Turkish scholars characterize Musa Bigiyev as a person who took a worthy place among outstanding Muslim intellectuals of the late$19^{th}$ – beginning of the

20$^{th}$century, the researcher who laid down new guidelines during the times of global turmoil, conflicts and wars.

This major collaborative conference, undoubtedly, turns a new page in mutual cultural cooperation of the two related peoples. Now, it is important to make the most of the scientific and educational links established between teachers, researchers and academic institutions.

---

In May 13-17, it was the turn of the Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan Federal University to receive the baton of significant events which were held as a part of an ambitious program "Kazan is a cultural capital of the Turkic world, 2014". The international symposium "The Outstanding Educators of the Turkic World: Mehmet Akif Ersoy and Gabdulla Tukay" ("Türk dünyasini aydinlatanlar: Mehmet Akif Ersoy ve Gabdulla Tukay") will go into the annals of this year as one of the most important scientific events.

The symposium was aimed at studying and disseminating literary and scientific achievements of the eminent persons of the Turkic world. The multifaceted work of the famous poets of the Turkic world – Mehmet Akif Ersoy (Mehmet Akif Ersoy) and G.Tukay – was the focus of the academicians' attention. The Turkish delegation presented extensive data on the work of the great Ottoman poet and the author of the "March of Independence" (Turkey anthem), a teacher, a social activist, a religious enlightener Mehmet Akif Ersoy (1873-1936).

The fact, that the scientists from well-known universities of the Turkic world took part in the symposium, testifies to the magnitude of the event. The speeches of scholars from Turkish universities (Ankara University, the University of Istanbul, Marmara University, Aydin University, etc.) were devoted both to the study of the multifaceted work of Mehmet Akif Ersoy and to the issues of the Tatar-Turkish relations on language, literature and culture. Interesting presentations were made by the scholars from the University of Yunus Emre (Novopazar, Serbia), the University of Macedonia (Uzkup), the University of Yunus Emre (Baku, Azerbaijan), Tashkent University (Uzbekistan), Baku State University (Baku), Kyrgyz-Turkish University "Manas" (Bishkek), etc.

The symposium was attended by academicians from Tatarstan, Bashkortostan, and Moscow. Tatarstan scholars' presentations, which aroused great interest among Turkish colleagues, were dedicated to the multifaceted work of the great son of the Tatar people – G.Tukay and his contemporaries. The reports on the creative work of the famous Tatar educators such as Shigabutdin Marjani, Kayum Nasyri, Rizautdin Fakhrutdinov, Fatikh Karimi, Attaullah Bayazitov and others, enlarged the wealth of information about the work of the educators of the Turkic world.

Within the framework of the conference, Gabdulla Tukay Department of Tatar Philology and Intercultural Communication of Kazan Federal University, organized an exhibition dedicated to the life and work of Mehmet Akif Ersoy, among the exhibits were portraits of famous Turkish educators. The University received a gift of books by Tatar writers (about 30 books), published in the 19$^{th}$ century both in Turkey and in Europe, books from the personal fund of well-known Turkish collector Mehmet Ruyan Soydan (Mehmet Rüyan Soydan, Istanbul), a member of Mehmet Akif Ersoy Foundation Board of Philosophy and Arts.

The visit to the Bulgar Historical and Architectural Reserve and Ak Mosque, the Kazan Kremlin and the G.Tukay Museum made a lasting impression on the participants.

The joint large-scale scientific forum of this kind will lay a good foundation for further joint research, and will open up new prospects for the development of collaboration between higher education institutions in the scientific and cultural spheres.

---

On May 27-28, 2014 Kazan Federal University hosted the international scientific conference "The Turkic-Muslim world: identity, heritage and prospects of study: the 80th anniversary of Professor M.A.Usmanov". This year marks the 80th anniversary of the birth of the prominent turkologist, historian, archeographer, orientalist and organizer of science Mirkasymov Abdulahatovich Usmanov. Moreover, the conference was dedicated to the 50th anniversary of the founding of the Kazan University Archaeographic expedition – the phenomenon was unique and inimitable in the former USSR.

The conference brought together scholars from different countries – Hungary, Germany, Holland, Kazakhstan, the USA, Taiwan and Turkey, as well as representatives of academic schools of Moscow, St. Petersburg and the Russian Federation regions – friends, colleagues, students and supporters of M.A.Usmanov, more than 80 people.

The commemorative plenary session of the conference was opened by I.A.Gilyazov, the Head of the Tatar Studies Department of the Institute of International Relations, History and Oriental Studies. He said that M.A.Usmanov was an iconic figure of Tatar historical science in the twentieth to the beginning of the twenty-first century. And this conference is not only a tribute to an outstanding scientist, but also a great impetus for the further study of the Turkic-Muslim world.

Subsequent speakers at the plenary session were L.N.Latypov, KFU Vice-Rector for International Affairs, President of the Russian Society of Orientalists, R.N.Valliullin, First Deputy Chairman of the Executive Committee of the Congress of Tatars, G.R.Nazipova, the director of the National Museum of Tatarstan, N.A.Kambeev, the Director of the National Library of the RT, I.A.Mustakimov, the Chief of the Department of Scientific Use of Archival Documents and International Relations of the Main Archival Administration under the Cabinet of Ministers of the Republic of Tatarstan, Z.S.Minullin, a member of the Foundation Board "Zhyen", G.S.Sabirzyanov, Deputy Director of the Institute of Tatar Encyclopedia. The welcome address of Mikhail Piotrowski, Director of the State Hermitage, was voiced by M.G.Kramarovskii, the leading researcher of the Hermitage. Then, the conference participants were warmly welcomed by R.M.Munchaev, a RAS Corresponding Member and I.V.Zaytsev, the Deputy Director of the Institute of Oriental Studies, in the form of video greetings.

The keynote speech at the plenary session was made by R.R.Khairutdinov, the Director of the Institute of International Relations, History and Oriental Studies, who told the assembled guests about the academic career of his teacher Mirkasymov Abdulahatovich.

The conference had several sections: "Personality in History: scientific and social heritage of M.A.Usmanov", "Eastern Archeology in Russia and the issues of Source Studies", "Turkic-Muslim heritage of the Golden Horde", "Tatar theological thought and Muslim spiritual and political institutions", "Islam in the Middle Ages and modern times: the issues of Source Studies", "Islamic book tradition and Tatar literature". These areas of study correspond to the scientific interests of Mirkasymov Abdulahatovich Usmanov. More than 50 speeches were made and many of them excited great interest of the participants.

During the conference, all the participants had the opportunity to acquaint colleagues with their achievements and discuss the prospects of current research.

---

After the changes that took place at the end of the 20$^{th}$ century and the beginning of the 21$^{st}$ century, intercultural communication between Tatarstan and Turkey has been successfully resumed. Mostly, it is due to the activities of the International Organization of Turkic Culture which was established in 1993. Interaction in the sphere of culture has become the basis for the development of scientific links.

Of special importance is the research of Tatar scholars in the area of Tatar-Turkish connections: many articles about literary-cultural and social-spiritual communication have been published; voluminous monographs and theses have been written.

Scientific symposiums and conferences play an important role in establishing contact between the scholars of Tatarstan and Turkey as well as in the renewal of historical connections and the development of scientific research. The participation of Tatar scholars in conferences organized by Turkish universities, and collaboration in the sphere of scientific research have made major contributions to the prosperity of both scientific worlds. Regular participation of Tatar scholars in annual conferences organized by Türk Dil Kurumu, is the evidence of this mutually beneficial collaboration.

Joint Intercultural Conferences on Turkology, Turkic literature and history have been very productive. For example, in 2014, Kazan was declared a cultural capital of the Turkic world and on the 13-14th of May 2014, the Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan Federal University was hosting a significant event – an international symposium "The Outstanding Educators of the Turkic World: Mehmet Akif Ersoy and Gabdulla Tukay" ("Türk dünyasini aydinlatanlar: Mehmet Akif Ersoy ve Gabdulla Tukay") which was held as part of an ambitious program "Kazan is a cultural capital of the

Turkic world, 2014". It was an intercultural dialogue about national life, national consciousness and pride based on the example of these great sons of the Turkic world.

After this forum, which took place in Kazan, famous scholars of the Turkic world gathered in Eskisehir in Turkey. The event "Türk Dünyası Bilgeler Zirvesi" (May 26-28), organized by Osmangazi University of Eskisehir, was devoted to the outstanding personalities of the Turkic people – Khodzha Ahmad Yasavy (1105-1166), Yunus Amre (1240-1320/21), Mevlana Zhalaletdin Rumy (1207-1273), Badiuzaman Sayet Nursy (1878-1960). The event aimed at the popularization of these poets and philosophers, the search for the spiritual ideal, and spiritual unity of the Turkic people. The rector of Osmangazi University, Professor Dr.Khasan Gunen, called these famous personalities "a balm for the soul" and highly appreciated their work, having noted that they were great philosophers, and for us, they should be an example to follow. The forum was attended by approximately five hundred world famous people: scholars, writers, artists, public servants, representatives of religion, journalists and politicians. Among the participants, there were scholars from Azerbaijan, America, India, Iran, Iraq, Kazakhstan, China, Pakistan, Russia (Tatarstan, Bashkortostan), Uzbekistan, and the fact testifies to the magnitude of the event. In addition to artistic heritage discussions, the speakers introduced to the audience outstanding personalities of their nations, those who glorified their motherland. In this forum, Tatarstan was represented by F.Yu.Yusupov and F.S.Saifulina, Professors of the Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan Federal University. Their reports were devoted to Gabdulla Tukai, the great Tatar poet who devoted his life and creative work to the Tatar people.

*The information was submitted by A.Gilyazov, Doctor of History, Professor of the Institute of International Relations, History and Oriental Studies, Kazan Federal University, F.S.Sayfullina, Doctor of Philology, Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University, and A.M.Ahunov, PhD in Philology, Associate Professor of the Institute of International Relations , History and Oriental Studies, Kazan Federal University.*

# 2014 ЕЛДА БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР

Мәгълүм булганча, 2014 нче елда Казан төрки дөньяның мәдәни башкаласы буларак игълан ителде. Әлеге мөһим карар кысаларындагы беренче зур халыкара чара Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтында үткәрелде. 18-19 нчы апрель көннәрендә «Татар җәмгыятендә туган җәдидчелек феномены: Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Муса Җаруллаһ Бигиев» дип аталган халыкара фәнни конференция булып узды.

«Дерсаадет» Истанбул үзәге, Төркиянең югары университетлары, илнең гыйльми җәмәгатьчелеген тәкъдим иткән төрек даирәсе Казан университеты белән берлектә фәнни форум үткәрү теләген белдерделәр, чөнки нәкъ менә әлеге тарихи уку йорты төбәктә көнчыгышны өйрәнү, тюркология, татар тел гыйлемен тикшерү өлкәләрендә алдынгы урында тора.

Төрек җәмәгатьчелеге ягыннан әлеге чарада 70 кә якын кеше катнашты, Төрек коллегаларыбыз татар проблематикасы белән шөгыльләнгән барлык белгечләрне бергә туплауга ирешкән. Симпозиум эшендә Казан галимнәре – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең профильле институтлары, Татарстан башкаласының уку йортлары галимнәре, Россия ислам институты, ТР мөселманнарының Диния нәзарәте һ.б. хезмәткәрләр катнаштылар.

Ике көн дәвам иткән конференция эшендә россия-төрек бәйләнешләре тарихына, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы төрки-мөселман җәмгыятендә барган яңарыш процессында күренекле татар җәмәгать һәм дин эшлеклеләренең роленә бәйле күп төрле мәсьәләләр тикшерелде. Конференция эше Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, М.Бигиевкә багышланган 3 тематик секциягә бүленеп алып барылды.

Беренче секциядә Ш.Мәрҗанинең тормышы һәм фәнни эшчәнлеген өйрәнү белән шөгыльләнгән күренекле галимнәр чыгыш ясады. Аларның докладларында җәдидчелек хәрәкәтен башлап җибәрүчеләрнең берсе булган Ш.Мәрҗанинең уникаль һәм күпьяклы хезмәтләре яктыртылды. Аның идея-фәлсәфи карашлары, педагог, дин әһеле, тарихчы, мәгърифәтче, философ буларак эшчәнлеге төрки халыклар тарихында күренекле эз калдыруы ассызыклап үтелде.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башының тагын бер күренекле дин белгече, энциклопедист галиме Ризаэтдин Фәхретдингә багышланган секциядә шулай ук кызыклы чыгышлар булды. Үзенең социаль-фәлсәфи карашлары белән гуманист булган Р.Фәхретдиннең әхлак, гаделлек, тигез хокуклылык мәсьәлләренә зур игътибар бирүе, мөселман җәмгыятендә хатын-кыз һәм гаилә проблемаларына күпсанлы хезмәтләр багышлавы ассызыклап үтелде.

Күренекле татар дин галиме, реформатор Муса Җаруллаһ Бигиевкә багышланган секциядә яңа һәм кызыклы мәгълүматлар яктыртылды. Төрек галимнәре фикеренчә, Муса Бигиев XIX гасыр ахыры – XX гасыр башының танылган мөселман интеллектуаллары рәтендә, дөньякүләм үзгәрешләр, каршылыклар һәм замана ыгы-зыгылары чорында яңа юнәлешләр формаштырган галимнәр арасында лаеклы урын тота.

Киң масштаблы конференция үткәрү ике тугандаш халыкның үзара мәдәни хезмәттәшлегенең, һичшиксез, яңа сәхифәләрен ача. Хәзерге вакытта укытучылар, фәнни хезмәткәрләр һәм академик оешмалар арасындагы фәнни һәм белем бирү потенциалын максималь файдалану мөһим.

---

«Казан – төрки дөньяның 2014 нче ел мәдәни башкаласы» программасы кысаларында үткәрелгән чаралар эстафетасы 13-17 нче май көннәрендә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтына да килеп җитте. «Танылган мәгърифәтчеләр Мәхмәт Акиф Эрсой һәм Габдулла Тукай» Халыкара симпозиумы («Türk dünyasini aydinlatanlar: Mehmet Akif Ersoy ve Gabdulla Tukay») ел тарихына әһәмиятле фәнни чараларның берсе булып кереп калды.

Симпозиум күренекле төрки дөнья вәкилләренең әдәбият һәм фән өлкәсендәге уңышларын өйрәнү һәм аны фәнни даирәгә танытуга багышланды. Бөтен төрки дөньяга танылган шагыйрьләр Мәхмәт Акиф Эрсой (Mehmet Akif Ersoy) һәм Габдулла Тукайның күпкырлы эшчәнлеге фәнни җәмәгатьчелекнең төп игътибар үзәгендә булды. Төрек коллегаларыбыз бөек осман шагыйре,

«Бәйсезлек маршы» (Төркия гимны) авторы, педагог, җәмәгать эшлеклесе, дини мәгърифәтче Мәхмәт Акиф Эрсой (1873-1936) иҗаты турында бай материал тәкъдим итте.

Симпозиум эшендә төрки дөньяның танылган югары уку йортларыннан килгән галимнәрнең катнашуы әлеге чараның киң масштабта үтүен дәлилли. Төркия университеты (Әнкара университеты, Стамбул университеты, Мәрмәр университеты, Фрат университеты, Айдын университеты һ.б.) галимнәренең чыгышлары күренекле якташлары Мәхмәт Акиф Эрсойның күпкырлы эшчәнлеген, шулай ук тел, әдәбият, мәдәният өлкәләрендә татар-төрек бәйләнешләрен өйрәнүгә багышланган иде. Симпозиум эшендә Юнус Эмре университеты (Сербия, Новопазар ш.), Македония университеты (Македония, Узкуп ш..), Юнус Эмре университеты (Әзербайҗан, Баку ш.), Ташкент университеты (Үзбәкстан, Ташкент ш.), Баку дәүләт университеты (Әзербайҗан, Баку ш.), «Манас» Кыргыз-Төрек университеты (Кыргызстан, Бишкек ш.) һәм башка университет галимнәре кызыклы докладлар белән чыгыш ясадылар.

Симпозиумда Татарстан, Башкортостан Республикаларыннан, Мәскәүдән дә галимнәр катнашты. Татарстан ягыннан булган татар халкының бөек улы Габдулла Тукайның һәм чордашларының күпкырлы талантына багышланган докладлар төрек коллегаларыбызда зур кызыксыну уятты. Татарның күренекле мәгърифәтчеләреннән – Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Гатаулла Баязитовларның иҗади эшчәнлегенә багышланган докладлар төрки дөнья мәгърифәтчеләре турындагы бай базаны яңа мәгълүмат белән тулыландырды.

Конференция кысаларында КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай үзәгендә Мехмет Акиф Эрсойның тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган һәм төрки мәгърифәтчеләребез портретлары күргәзмәләре ачылды. Татар язучыларының күренекле коллекционер һәм Мехмет Акиф Эрсой исемендәге фонд житәкчесе Мехмет Руйан Сойданның шәхси китапханәсендә сакланган XIX гасырда Төркиядә һәм Европада басылган китаплары (30лап китап) һәм күргәзмәдәге башка экспонатлар вузга тапшырылды.

Болгар тарихи-архитектура тыюлыгы, Ак Мәчет, Казан Кремле һәм Г.Тукай музее кунаклар хәтерендә онытылмас эз калдырды.

Массакүләм мәгълүмат чараларында зур кызыксыну уяткан масштаблы әлеге гыйльми форумны бергә үткәрү киләчәк эзләнүләргә зур адым булачак, вузлар арасында фән һәм мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү перспективаларын ачачак.

---

2014 нче елның 27-28 нче маенда Казан федераль университетында «Төрки-мөселман дөньясы: охшашлык, мирас, өйрәнү перспективалары: профессор М.Г.Госмановның 80 еллыгына» дип аталган халыкара фәнни конференция булып узды. Быел күренекле тюрколог, тарихчы, археограф, көнчыгышны өйрәнү фәнен нигезләүче галим Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановның тууына 80 ел. Әлеге конференция Казан университетының элекке СССР масштабларында уникаль булган Археографик экспедициягә нигез салынуга 50 ел тулуга да багышланган иде.

Конференциядә төрле чит илләрдән, аерым алганда, Венгрия, Германия, Голландия, Казахстан, АКШ, Тайвань, Төркия галимнәре, шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург фәнни мәктәпләре вәкилләре, Россия Федерациясе төбәкләреннән М.Госмановның дуслары, коллегалары, фикердәшләре – барлыгы 80 кеше катнашты.

Конференциянең тантаналы пленар утырышын Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих, көнчыгышны өйрәнү институтының татарны өйрәнү кафедрасы мөдире И.А.Гыйләҗев ачып җибәрде. Ул М.Г.Госмановның XX – XXI гасыр башы татар тарихы фәнендә күренекле шәхес булуын һәм бу конференциянең аның якты истәлегенә багышлануын һәм барыннан да бигрәк, бу чараның төрки-мөселман дөньясын өйрәнү эшенә зур этәргеч бирүен ассызыклап үтте.

Пленар утырышны КФУның халыкара эшчәнлек буенча проректоры, Россиянең Көнчыгышны өйрәнүче галимнәре җәмгыяте президенты Л.Н.Латыпов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р.Н.Вәлиуллин, ТРның Милли музей директоры Г.Р.Нәҗипова, ТРның Милли китапханә директоры Н.А.Камбеев, Татарстан Республикасының Министрлар кабинеты каршында Баш архив идарәсенең архив документларны фәнни куллану һәм халыкара бәйләнешләр секторы мөдире И.А.Мөстәкыймов, «Жыен» фонды идарәсе әгъзасы Җ.С.Миңнуллин, Татар энциклопедиясе институты директоры урынбасары Г.С.Сабирҗанов катнаштылар. Дәүләт

Эрмитажы директоры М.Б.Пиотровскийның сәламләү сүзен Эрмитажның өлкән фәнни хезмәткәре М.Г.Крамаровский җиткерде. Аннан соң конференциядә катнашучыларга Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү Институты әгъза-корреспонденты Р.М.Мунчаев һәм директор урынбасары И.В.Зайцев видеосәламләү сүзе белән мөрәҗәгать иттеләр.

Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих, көнчыгышны өйрәнү институты директоры Р.Р.Хәйретдинов төп доклад белән чыкты. Ул үз чыгышында кунакларны остазы Миркасыйм Габделәхәт улының фәнни хезмәт юлы белән таныштырды.

Конференция эше берничә секциягә бүленеп алып барылды: «Тарихта шәхес: М.Г.Госмановның фәнни һәм иҗтимагый мирасы», «Россиядә көнчыгыш археография һәм чыганакчылык белеме проблемалары», «Алтын Урданың төрки-мөселман мирасы», «Татар дини фикере һәм мөселман рухани, сәяси институтлары», «Урта гасырда һәм хәзерге чорда Ислам: чыганакчылык белеме проблемалары», «Ислам китап традициясе һәм татар әдәбияты». Бу юнәлешләр Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановның төп фәнни мәнфәгатьләренә туры килә. Барлыгы 50 доклад тыңланды һәм аларның күпчелеге аудиториядә зур кызыксыну уятты.

Конференция вакытында барлык катнашучылар коллегаларын үзләренең уңышлары белән таныштыру һәм көнүзәгендәге фәнни тикшеренү перспективаларын уртага салып сөйләшү мөмкинлегенә ия булдылар.

---

Илдәге мәгълүм үзгәрешләр нәтиҗәсендә XX гасыр ахыры - XXI гасыр башларында Төркия һәм Татарстан арасында мәдәни багланышларны яңадан тергезү юнәлешендә җитди уңышларга ирешелде. Бу багланышларның ныгуы аеруча 1993 нче елда оештырылган Халыкара төрки мәдәниятләр оешмасы (ТӨРКСОЙ) эшчәнлеге белән бәйле. Мәдәният өлкәсендә башланган аралашу әкренләп фәнни багланышлар урнаштыруга да ныклы җирлек әзерләде.

Татар әдәбият белеме галимнәренең татар-төрек халыклары арасындагы бәйләнешләрне өйрәнү юнәлешендә эзләнүләре аеруча нәтиҗәле булды: әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый-рухи бәйләнешләрне яктырткан күпсанлы мәкаләләр дөнья күрде, күләмле монографияләр һәм диссертацияләр язылды.

Татарстан һәм Төркия галимнәре арасында фикер алышуда, тарихи багланышларны тергезү һәм фән өлкәсендә үсеш юлларын билгеләүдә фәнни симпозиум, конференцияләрнең роле зур. Төркия югары уку йортлары тарафыннан оештырылган конференцияләрдә республика галимнәренең фәнни чыгышлар белән катнашуы, татар дөньясындагы гыйльми-нәзари фикерне төрек кардәшләребезгә җиткерү, шуның белән бергә төрек дөньясында танылу ике якның да фән үсеше өчен файдалы һәм кирәкле эш булып тора. Türk Dil Kurumu тарафыннан ел саен оештырыла торган конференцияләрдә татар галимнәренең даими катнашуы - багланышлар ныгуының ачык мисалы.

Тюркология, төрки халыклар әдәбияты, тарихы мәсьәләләренә багышланган халыкара конференцияләрне ике ил галимнәре бергәләп оештыруның да уңай нәтиҗәләре бар. 2014 нче елда Казан – төрки дөньяның мәдәни башкаласы дип игълан ителү уңаеннан, дөньякүләм зур чаралардан торган программа кысаларында Казан университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты тарафыннан оештырылган «Төрки дөньяның танылган шәхесләре: Мехмет Акиф Эрсой һәм Габдулла Тукай» халыкара симпозиумы («Türk Dünyasını aydınlatanlar: MehmetAkif Ersoy ve Gabdulla Tukay«) шундый зур фәнни форумнарның берсе булды. Г.Тукай һәм М.А.Эрсой кебек бөек шәхесләр мисалында галимнәр милли яшәеш, милли үзаң, милли горурлык, үз халкыңа хезмәт итү кебек һәр ике ил өчен бүгенге көндә дә кыйммәтле булган төшенчәләр хакында фикер алышты.

Агымдагы елның 13-18 нче май көннәрендә Казанда үткәрелгән шушы форумнан соң, төрки дөньяның атаклы галимнәре Төркиянең 2013 нче елда Төрки халыклар мәдәни башкаласы дип танылган Искешәһәр каласында зур очрашуга җыелды. Османгази Университеты тарафыннан оештырылган «Türk Dünyası Bilgeler Zirvesi» (26-28 май) дип аталган саммит төрки халыкларда танылган шәхесләр – Хуҗа Әхмәт Йәсәви (1105 тирәсе-1166), Юныс Әмре (1240 тирәсе-1320/21), Мәвлана Җәлалетдин Руми (1207-1273), Бәдиузаман Сәет Нурси (1878-1960) кебек мәгърифәт-гыйлем ияләре истәлегенә багышланды. Саммит барышында суфи-шагыйрь, бөек акыл иясе, фәлсәфәче буларак билгеле шушы исемнәрне бүгенге көндә популярлаштыру, алар тормышы

мисалында бүгенге катлаулы заманада рухи таяныч эзләү, шушы нигездә төрки халыкларны рухи берләштерү, бер юнәлештә, аңлашып яшәү мөмкинлеген ачыклау максаты куелды. Искешәһәрнең Османгази университеты ректоры профессор, доктор Хәсән Гөнен бу шәхесләрне "күңелләр солтаны" дип атады һәм аларның фәлсәфи карашлы, тирән фикерле, рухыбызны сафландыра торган хезмәтләре киләчәккә барыр юлыбызда да юнәлеш бирерлек дип зур бәя бирде. Дөньякүләм танылган галимнәрне, әдипләрне, рәссамнарны, җәмәгать-дәүләт эшлеклеләрен, дин әһелләрен, журналистларны, сәясәтчеләрне берләштергән бу фәнни форумда 500 гә якын кеше катнашты. Төркиянең күпсанлы университетлары галимнәре белән берлектә Әзербәйҗан, Америка, Һиндстан, Иран, Ирак, Казахстан, Кытай, Пакистан, Русия (Татарстан, Башкортостан), Үзбәкстан һ.б. илләрдән дә 150 гә якын галимнәр чакырылган булуы саммитның зур колачлы булуын раслый. Аталып үтелгән шәхесләрнең иҗат мирасын барлау, аларның күпкырлы эшчәнлегенә бүгенге көн карашларыннан чыгып бәя бирү белән беррәттән, фәнни доклад авторлары шулай ук саммитта катнашучыларны үз халыкларын дөньяга таныткан шәхесләр эшчәнлеге белән дә таныштырды. Татарстаннан бу форумда Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессорлары Ф.Ю.Юсупов, Ф.С.Сәйфулиналар катнашты. Аларның чыгышларында тормышын һәм иҗатын татар халкына хезмәткә багышлаган Габдулла Тукай шәхесенең бөеклеге хакында фикерләр яңгырады.

*Материалларны тарих фәннәре докторы, Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты профессоры И.А.Гыйләҗев, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры Ф.С.Сәйфуллина, Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты доценты А.М.Ахунов әзерләде.*

# СОБЫТИЯ, КОТОРЫЕ ПРОИЗОШЛИ В 2014 ГОДУ

Как известно, в 2014 году Казань стала культурной столицей тюркского мира. Первое крупное международное мероприятие в рамках этого важного решения прошло в Казанском федеральном университете, где 18-19 апреля на базе Института международных отношений, истории и востоковедения состоялась международная научная конференция «Феномен татарского джадидизма: Шигабутдин Марджани, Ризаэтдин Фахретдин, Муса Джаруллах Бигиев».

Турецкая сторона, представленная стамбульским центром «Дерсаадет», крупнейшими университетами Турции, научной общественностью этой страны, выразили желание провести научный форум совместно с Казанским университетом, поскольку именно это старейшее учебное заведение занимает в регионе лидирующие позиции в области востоковедения, тюркологии и татароведения.

С турецкой стороны в мероприятии приняло участие около 70 человек. Турецким коллегам удалось собрать почти всех специалистов, которые занимаются татарской проблематикой. В симпозиуме приняли участие и казанские ученые – представители профильных институтов Академии наук РТ, других вузов столицы Татарстана, сотрудники Российского исламского института, Духовного управления мусульман РТ и др.

На самой конференции, которая длилась два дня, обсуждался широкий круг вопросов, связанных с историей российско-турецких отношений, тюркской культурой, ролью известных татарских общественных и религиозных деятелей в обновленческих процессах тюрко-мусульманского общества в конце XIX – начале XX века. Работа конференции была поделена на три тематические секции, посвященные Ш.Марджани, Р.Фахретдину, М.Бигиеву.

В первой секции выступили известные турецкие ученые, занимающиеся изучением жизни и научного творчества Марджани. В их докладах нашли отражение уникальные и многогранные направления деятельности предвестника джадидского движения. Было сказано, что идейно-философские взгляды Марджани, его деятельность в качестве педагога, религиозного деятеля, историка, просветителя, философа останутся заметным явлением в истории тюркских народов.

Весьма интересными были выступления на секции, посвященной еще одному видному ученому-богослову и энциклопедисту конца XIX – начала XX века Ризаэтдину Фахретдину. Было отмечено, что в своих социально-философских воззрениях Р.Фахретдин выступал как гуманист, уделял большое внимание вопросам нравственности, справедливости и равноправия, немало работ посвятил проблеме женщины в мусульманском обществе и теме семьи.

Много нового и интересного можно было узнать на секции, посвященной выдающемуся татарскому богослову и реформатору Мусе Джаруллаху Бигиеву. По мнению турецких ученых, Муса Бигиев – это человек, который занимал достойное место в ряду выдающихся мусульманских интеллектуалов конца XIX – начала XX века, ученых, которые формировали новые ориентиры в период мировых потрясений, конфликтов и войн того времени.

Проведение столь масштабной совместной конференции, несомненно, открывает новую страницу во взаимном культурном сотрудничестве двух родственных народов. Теперь очень важно максимально использовать потенциал научных и образовательных связей между преподавателями, исследователями и академическими учреждениями.

---

Эстафета значимых мероприятий, проводимых в рамках обширной программы «Казань – культурная столица тюркского мира 2014 года», 13-17 мая перешла к Институту филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета. Международный симпозиум «Выдающиеся просветители тюркского мира: Мехмет Акиф Эрсой и Габдулла Тукай» («Türk dünyasini aydinlatanlar: Mehmet Akif Ersoy ve Gabdulla Tukay») войдет в летопись данного года как одно из значимых научных мероприятий.

Симпозиум был направлен на изучение и распространение литературных и научных достижений видных деятелей тюркского мира. В центре внимания ученых находилась многогранная деятельность известных всему тюркскому миру поэтов – Мехмета Акифа Эрсоя (Mehmet Akif Ersoy) и Габдуллы Тукая. Турецкая сторона представила обширный материал по творчеству вели-

кого османского поэта, автора «Марша независимости» (гимна Турции), педагога, общественного деятеля, религиозного просветителя Мехмета Акифа Эрсоя (1873-1936).

Масштабность мероприятия подтверждается участием в работе симпозиума ученых, приехавших из известных вузов Тюркского мира. Выступления ученых из университетов Турции (университет Анкары, Стамбульский университет, Мармаринский университет, Фратский университет, Айдынский университет и др.) были посвящены как исследованию разносторонней деятельности Мехмата Акифа Эрсоя, так и вопросам татаро-турецких взаимосвязей в области языка, литературы и культуры. С интересными докладами выступили ученые из Университета Юнуса Эмре, (Сербия, г.Новопазар), Университета Македонии (Македония, г.Узкуп), Университета Юнуса Эмре (Азербайджан, г.Баку), Ташкентского университета (Узбекистан, г.Ташкент), Бакинского государственного университета (Азербайджан, г.Баку), Кыргызско-Турецкого университета «Манас» (Киргизия, г.Бишкек) и др.

В симпозиуме приняли участие ученые из Татарстана, Башкортостана, Москвы. Выступления татарстанских ученых, вызвавшие живой интерес у турецких коллег, были посвящены многогранной деятельности великого сына татарского народа Габдуллы Тукая и его современников. Доклады, посвященные творческой деятельности известных татарских просветителей Шигабутдина Марджани, Каюма Насыри, Ризаутдина Фахрутдинова, Фатиха Карими, Атауллы Баязитова и др. пополнили богатейшую информацию о деятельности просветителей тюркского мира новыми данными.

В рамках конференции в Центре Г.Тукая Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета была открыта выставка, посвященная жизни и деятельности Мехмета Акифа Эрсоя, а также выставка портретов известных тюркских просветителей. Наряду с книгами татарских писателей (около 30 книг), изданных в XIX веке как в Турции, так и в Европе, вузу были подарены книги из личного фонда известного коллекционера Турции, члена правления фонда Философии и искусства им. Мехмета Акифа Эрсоя Мехмета Руйана Сойдана (Mehmet Rüyan Soydan, Стамбул), а также представленные на выставках экспонаты.

Неизгладимое впечатление произвело на гостей посещение Болгарского государственного историко-архитектурного музея-заповедника и Ак Мечети, Казанского кремля и музея Габдуллы Тукая.

Совместное проведение столь масштабного научного форума станет хорошей основой для дальнейших совместных изысканий, откроет перспективы развития сотрудничества между вузами в области науки и культуры.

---

27-28 мая 2014 года в Казанском федеральном университете прошли заседания международной научной конференции «Тюрко-мусульманский мир: идентичность, наследие и перспективы изучения: к 80-летию профессора М.А.Усманова». В этом году исполнилось 80 лет со дня рождения выдающегося ученого-тюрколога, историка, археографа, востоковеда, организатора науки Миркасыма Абдулахатовича Усманова. Кроме того, конференция была приурочена к 50-летию со дня основания Археографической экспедиции Казанского университета – явления уникального в масштабах всего бывшего СССР.

В конференции приняли участие ученые из различных стран – Венгрии, Германии, Голландии, Казахстана, США, Тайваня, Турции, а также представители научных школ Москвы, Санкт-Петербурга, регионов Российской Федерации – друзья, коллеги, ученики, единомышленники М.А.Усманова, всего более 80 человек.

Торжественное пленарное заседание конференции открыл заведующий кафедрой татароведения Института международных отношений, истории и востоковедения И.А.Гилязов. Он отметил, что М.А.Усманов – выдающаяся фигура татарской исторической науки XX – начала XXI века, и настоящая конференция является не только данью памяти выдающемуся ученому, но и придает огромный импульс дальнейшей работе по изучению тюрко-мусульманского мира.

На пленарном заседании вступили также проректор КФУ по международной деятельности, президент Общества востоковедов России Л.Н.Латыпов, Первый заместитель Председателя Исполкома Всемирного конгресса татар Р.Н.Валиуллин, директор Национального музея РТ Г.Р.Назипова, директор Национальной библиотеки РТ Н.А.Камбеев, заведующий сектором науч-

ного использования архивных документов и международных связей Главного архивного управления при Кабинете Министров Республики Татарстан И.А.Мустакимов, член правления фонда «Жыен» З.С.Минуллин, заместитель директора Института Татарской энциклопедии Г.С.Сабирзянов. Приветственный адрес директора Государственного Эрмитажа М.Б.Пиотровского озвучил ведущий научный сотрудник Эрмитажа М.Г.Крамаровский. Затем к участникам конференции с видеоприветствием обратились член-корреспондент РАН Р.М.Мунчаев и заместитель директора Института востоковедения РАН И.В.Зайцев.

Основной доклад на пленарном заседании сделал директор Института международных отношений, истории и востоковедения Р.Р.Хайрутдинов, который рассказал собравшимся гостям о научном пути своего учителя Миркасыма Абдулахатовича.

Работа конференции была организована по нескольким секциям: «Личность в истории: научное и общественное наследие М.А.Усманова», «Восточная археография в России и проблемы источниковедения», «Тюрко-мусульманское наследие Золотой Орды», «Татарская богословская мысль и мусульманские духовные и политические институты», «Ислам в средневековье и новое время: проблемы источниковедения», «Исламская книжная традиция и татарская литература». Выбор этих направлений соответствовал основным научным интересам самого Миркасыма Абдулахатовича Усманова. Всего было заслушано более 50 докладов, многие из которых вызвали большой интерес аудитории.

Во время конференции все участники имели возможность познакомить коллег со своими достижениями, обсудить перспективы актуальных научных исследований.

---

Конец XX – начало XXI века во взаимоотношениях Татарстана и Турции является временем укрепления культурных взаимосвязей, обмена достижениями в различных областях культуры. Успешное развитие международных отношений в этом направлении было во многом обусловлено деятельностью Международной Организации по Совместному Развитию Тюркской Культуры и Искусства (ТЮРКСОЙ), созданной в 1993 году. Сотрудничество в области культуры послужило фундаментом для развития научных связей.

Особенно результативными оказались изыскания татарских литературоведов, изучавших взаимосвязи между тюркскими народами: были опубликованы многочисленные статьи, защищены диссертационные исследования, увидели свет монографии, посвященные этой тематике.

Важную роль в восстановлении исторических связей Татарстана и Турции, создании условий для взаимного диалога, определении перспектив сотрудничества сыграли научные симпозиумы, конференции. Выступая с докладами на научных мероприятиях, организованных вузами Турции, наши ученые знакомили научную общественность с татарской научно-теоретической мыслью, что способствовало формированию позитивного имиджа татарстанских ученых в тюркском мире и имело важное значение для плодотворного развития науки как в Турции, так и Татарстане. Ярким примером такого сотрудничества стало постоянное участие татарских ученых в мероприятиях, ежегодно организуемых Фондом Тюркского языка.

Совместная организация учеными двух стран международных конференций, посвященных вопросам тюркологии, литературы тюркских народов и их истории, также имела плодотворные результаты. В связи с тем, что в 2014 г. Казань была объявлена культурной столицей тюркского мира, Институтом филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета был организован международный симпозиум «Выдающиеся люди тюркского мира: Мехмет Акиф Эрсой и Габдулла Тукай» («Türk Dünyasını aydınlatanlar: MehmetAkif Ersoy ve Gabdulla Tukay»), который стал одним из крупных форумов в Программе всемирных мероприятий, где ученые обсудили очень важные для двух стран проблемы национального бытия, национального самосознания, национального достоинства, служения своему народу.

13-18 мая 2014 года, после проведения в Казани данного форума, известные ученые тюркского мира собрались в турецком г.Эскишехир, объявленном культурной столицей тюркского мира 2013 года. Научный саммит «Türk Dünyası Bilgeler Zirvesi», организованный 26-28 мая Университетом Османгази, был посвящен памяти таких известных в тюркском мире просветителей, как Ахмед Ясави (ок.1105-1166), Юнус Эмре (ок.1240-1320/21), Мавляна Джалалетдин Руми (1207-1273), Бадиуззаман Саид Нурси (1878-1960). На саммите обсуждались проблемы популяризации

наследия известных поэтов-суфиев, великих мыслителей, философов, пути обретения в наши сложные времена духовной опоры и идеалов на примере их жизни, что способствовало бы объединению тюркских народов и достижению взаимопонимания между ними. Ректор Университета Османгази (Эскишехир) Хасан Гюнен назвал эти личности «султанами душ» и выразил надежду на то, что их труды, насыщенные философскими взглядами, глубокими мыслями, будут способствовать духовному оздоровлению общества и, став своего рода идеалом, помогут наметить ориентиры на будущее. В этом научном мероприятии приняли участие около 500 человек из числа всемирно известных ученых, писателей, художников, общественно-политических, религиозных деятелей, журналистов. Наряду с представителями университетов Турции, на саммите присутствовали ученые из Азербайджана, США, Индии, Ирана, Ирака, Казахстана, Узбекистана, Китая, Пакистана, России (Татарстан, Башкортостан) и других стран – всего около 150 человек. Таким образом, общее число участников свидетельствует о масштабности данного саммита. Доклады выступавших были посвящены изучению творческого наследия вышеназванных выдающихся личностей, их многогранной деятельности с точки зрения современности, в то же время слушатели имели возможность узнать о выдающихся деятелях культуры и просвещения других тюркских народов. На этом форуме Татарстан представляли Ф.Ю.Юсупов, Ф.С.Сайфулина – профессора Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета. Их выступления были посвящены деятельности Габдуллы Тукая, посвятившего жизнь и творчество служению татарскому народу.

*Материалы подготовлены И.А.Гилязовым, доктором исторических наук, профессором Института международных отношений, истории и востоковедения Казанского федерального университета; Ф.С.Сайфулиной, доктором филологических наук, профессором Института филологии и межкультуной коммуникации Казанского федерального университета; А.М.Ахуновым, кандидатом филологических наук, доцентом Института международных отношений, истории и востоковедения Казанского федерального университета*